СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2020 Баулы шәһәре № 274

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20

апрелендәге 149 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 176 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2020 елның 1 октябреннән түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары күләменнән чыгып исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары күләме 11498 сум тәшкил итә.».

2нче кушымтаны яңа редакциядә 1нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль
районы Советының 2020
елның 28 августындагы
274 номерлы карарына
1нче кушымта

Муниципаль район башлыгының, муниципаль район башлыгы урынбасарының һәм муниципаль районның контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата кбүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сум) |
|---|---|
| | 4нче төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 31 966,0 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 28 767,0 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 28 767,0 |